РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Урсаевского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл
җирлеге башкарма комитеты

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального
района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы,
423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30.01.2018

№2

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 15 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә һәм көтелмәгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү юнәлешләрен төгәлләштерү максатларында карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 15 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчаларны тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетының резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә, шул исәптән:

- һәлакәттән - стихияле бәла-казаларны, янгыннарны, башка гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә һәм аларны кисәтүгә бәйле төргызу эшләре һәм башка чаралар уздыру;

- гадәттән тыш хәлләрне булдырмау максатында кичектергесез эшләр башкару;

- гражданнар оборонасы, табигатьне саклау, җирле әһәмияттәге эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

- социаль-мәдәни өлкә, физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм итү;

- җирле әһәмияттәге юбилей, дини һәм башка чараларны үткәрү;

- җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга социаль ярдәм чаралары, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегендә дәүләтчелекне, җирле үзидарәне, икътисадны, сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын, фәнне, мәдәниятне, сәнгатьне, мәгарифне, сәламәтлек саклауны, спортны үстерүдәге, законлылыкны, хокук тәртибен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклауны тәэмин итүдәге һәм башка казанышлары өчен;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең бюджет өлкәсендә каралмаган башка чаралар һәм чыгымнар. ".

2. Әлеге карарны веб - адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http//pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында - http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык И.А.Абдуллин